СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

5 ноябрь, 1997 ел. ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 125 (8137) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ЭШ СӨЙГӘННЕ ИЛ СӨЯР




## Онкология белгече килде

Узган атнада районда Казан дәүләт медицина академиясенең онкология кафедрасы доценты, медицина фәннәре докторы И.Г. Гатауллин булып китте. Ул район табиблары алдында онкологик авырулар, аларны профилактикалау һәм дәвалау буенча лекцияләр укыды, шулай ук авырулар да кабул итте.

Ноябрьнең 10нан районга тагын онкология белгече килү көтелә.

## Гарәп графикасын өйрәнмисезме?

Теләге булганнарга хәбәр итәргә ашыгабыз: быелның 16 ноябреннән ир - егетләр һәм хатын - кызлар өчен гарәп графикасын һәм тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнү курслары эшли башлый.

Курсларда уку - бушлай, дәресләрне һәр елдагыча Ильяс Алишов алып барачак.


Укулар һәр якшәмбе иртәнге 8.30 сәг.тән 11.30 сәг.кә кадәр базар янындагы яңа мәчеттә үткәреләчәк.

## Тантана була

1997 елның 8 ноябрендә кичке сәгать 5тә район мәдәният йортында милиция көненә багышланган тантаналы җыелыш булачак. Җыелыштан соң концерт. Керү ирекле.

## ФОТО - РЕПОРТАЖ





Фомада Зәйнуллиннарның берсе туында да начар сүз ишетмәссең, Нәгыйм шикәр чөгендере игү остасы буларак танылса, Әсгать шулай ук уңган механизаторларның берсе. Әле моннан элек район газетасы призына ярыш оештырган чакта нәкъ менә Әсгатьнең язгы кыр эшләрендә көн туса нормасын арттырып үтәп барганлыгы яхшы хәтердә. Аның ул чактагы Т - 4 тракторы инде тузган икән, әмма гомерлек механизаторның тырышлыгы, булдыклылыгы, эш өчен янып - көеп йөрү гадәте генә элеккечә үк калган. Менә шуңа күрә быел куәтле К - 700 тракторына утырырга тәкъдим иткәч тә бер карусыз риза булды ул, уңышын җыеп алу озаккарак сузылу сәбәпле иң соңгы чутта, җир катыра башлагач эшкәртергә туры килгән чөгендер һәм кукуруз кырларын туңга сөрүдә дә намус белән эшләде.

**Рәсемнәрдә: «Игенче» хуҗалыгы механизаторы Ә.Зәйнуллин һәм аның сөрү агрегаты.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

## Бергә - бергә, өмә ясап

***Узган атнада район хакимияте карары нигезендә пәнҗешәмбе, җомга һәм шимбә көннәрендә чөгендергә массовый чыгу оештырылды. Удар өчкөнлек дәвамында шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары авыл эшчәннәренә зур ярдәм күрсәттеләр. Урыннардан хәбәрләр шул хакта.***

### ЧИСТАРТТЫЛАР, ТАШЫДЫЛАР

Норлат УТТсы үзе шефлык итүче хуҗалык «Алга» КХАна зур ярдәм күрсәтте. Ул көннәрдә идарә аппаратында эшләүче барлык хатын - кызлар да чөгендер чистарттылар, берничә «КамАЗ» автомашинасы татлы тамырны басудан шикәр заводына ташып торды. Идарә механизаторлары өчен дә эш табылды - терлекчелек объектларында су, ягулык системаларын төзекләндерделәр алар.

### ҖИҢ СЫЗГАНЫП

Октябрь район хезмәт һәм мәшгульлек бюросы коллективы да авылга ярдәмнән читтә калмады. Хатын - кызлар башта «Игенче» КХАсы хезмәтчәннәренә булышсалар, соңрак «Киекле» ассоциациясендә шикәр чөгендерен чистартуда җиң сызганып эшләделәр.

### ЯРДӘМ САЛЛЫ БУЛДЫ

«Норлат машина төзү заводы» акционерлык җәмгыятенең шеф хуҗалыгы - «Татарстан» КХАсы. Җәмгыять татарстанлыларга һәръяклы ярдәм күрсәтә. Әле менә удар өчкөнлек дәвамында да коллективтан 20дән артык кеше көн саен үз автобуслары белән Кычытканлыга йөрделәр. Авыл эшчәннәренә шикәр чөгендере чистартуда булыштылар алар. Кычытканлылар әйтүенчә, машина төзүчеләрнең ярдәме саллы булган.

### УКУ БЕЛӘН ХЕЗМӘТ ЯНӘШӘ

Бу мөһим чарадан район мәгариф бүлеге хезмәткәрләре һәм укучылар да читтә калмадылар.

Һәр көнне мәгариф бүлегеннән 20ләп кеше «Игенче» КХАсына юл алдылар. Алар чөгендер чистартуда эшләделәр, хәтта һава көйсезлекләре дә аларга киртә була алмады, бүлек хезмәткәрләре хуҗалыкка кулларыннан килгән ярдәмне күрсәттеләр.

**А.КОСТИН.**

## Үзидарә юлында

# АЛДА - ИКЕНЧЕ ТУР

***Октябрь азагында Мәскәү шәһәренең Красноярск муниципаль округында җирле үзидарәне үстерү механизмнарын эшләү буенча терәк группалар формалаштыру мәсьәләләре буенча Бөтенроссия семинары булды. Анда Норлат шәһәре җирле үзидарә Советы рәисе Р.Г.Билалов та катнашты. Безнең хәбәрчебезгә кыска әңгәмә вакытында ул менә нәләр сөйләде:***

- Семинарда муниципаль оешмаларның беренче туры конкурсына йомгак ясалды. Норлат Ярослав өлкәсенең Переславль - Залесский, Киров өлкәсенең Вятка Аланы кебек кече дип йөртелә торган өченче группа шәһәрләр группасына керде. Октябрь районы һәм безнең шәһәр Советында безнең территориянең социаль - икътисади үсеше дәрәҗәсе турында хәзерләнгән информация турда катнашуга керүнең үзенчәлекле балы итеп алынды. Минем белән бергә семинар эшендә Актүбә, Карабаш һәм Осиново поселокларындагы коллегаларым да катнашты... Россиянең берничә дистә өлкәләре һәм крайларыннан җирле үзидарәләр органнары җитәкчеләре катнашкан бу очрашуны Россия Федерациясенең милләтләр эше һәм федераль мөнәсәбәтләр буенча Министрлык үткәрде һәм аны Министр урынбасары А.Г.Воронов алып барды.

Беләсезме, бу уңайдан махсус законнар кабул ителсә дә, үзидарәгә юл әле формалашып кына килә. Шәһәр икътисадына ничек активрак итеп тәэсир итәргә? Кече бизнесны үстерү өчен уңай шартларны ничек формалаштырырга, нинди чыгымнар исәбенә җирле керемне үстерүне тәэмин итәргә? Муниципаль хуҗалык белән идарә итүнең төгәл һәм эшләнгән системасы булганда бу мәсьәләләрне уңай хәл итү мөмкин булачак. Шул җәһәттән галимнәр безгә булышырга теләп, хәзер муниципаль хакимиятне ныгытуның теоретик нигезләре өстендә эшлиләр. Иң мөһиме, бу практикадан аерылмыйча, конкрет шәһәр, районнар һәм эшчеләр поселокларының тәҗрибәсенә таянып эшләнелә. Шунсыз мөмкин түгел. Конкурс нигезендә терәк зоналар да шул максаттан чыгып формалаштырылды. Ә география киң иде. Дагыстан һәм Ямал - Ненец автономия округы да, Краснодар крае һәм Удмуртия, Тува һәм Свердлов өлкәсе... Шуңа конкурс группаларында аралашу, коллегаларымның чыгышлары, проблемалы мәсьәләләр буенча фикер алышулар - минем уемча, барысы да файдалы булды.

Алда икенче тур. Без анда да катнашачакбыз.

**Т.НАЗАРОВА язып алды.**

## Сез беләсезме?

### САННАР ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Якынча исәпләүләр буенча 1996 елда Татарстанда 3 млн. 766 меңнән артык кеше яши. 2 млн. 772 меңнән артыгы шәһәр җирендә, 994 меңе - авылда. Казан шәһәрендә - 1 млн. 85 мең.

Халык санын киметмичә, буыннарны табигый алыштырып тору өчен тууның суммар коэффициенты (бер хатын - кыздан туган балалар саны буенча) 2,15 - 2,17дән ким булмаска тиеш. Туу режимына карасак, 1990 елдан башлап, ул Татарстанда яшәүче халыкның гади буыннар алмашын да тәэмин итә алмый һәм 1,48гә кадәр кимегән.

## Игътибар: ярминкә

**6 ноябрь көнне шәһәрнең сәүдә мәйданында сәүдә предприятиеләре, крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциацияләре, оешма - предприятие сәүдә нокталары, эшмәкәрләр катнашында зур бәйрәм алды ярминкәсе була.**

**Ярминкә иртәнге 7дән эшли башлый. 9.00 сәг.тә халык өчен концерт, күңел ачу программасы башлана.**

# Татарстан Республикасы Конституциясенә - 5 ел

## Татарстан Республикасы Конституциясе - Татарстанда суверен дәүләтчелек ныгуда мөһим фактор

Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан 1992 елның 6 ноябрендә суверен Татарстанның яңа Конституциясен кабул итү Татарстан Республикасында мөстәкыйль дәүләтчелек барлыкка килү һәм үсешендә яңа этапны билгеләде.

Анда 1990 елның 30 августында Татарстан Республикасы мөстәкыйльлеге турында Декларациядә игълан ителгән суверенитет үзенең югары юридик ныгытмасын алды.

Беренче маддәдә үк Татарстан Республикасының суверен демократик дәүләт буларак республиканың күпмилләтле халкы ихтыярын һәм мәнфәгатен чагылдырган сәяси - хокукый табигате ныгытыла.

ТР Конституциясендә кеше хокуклары өстенлекләре, халыкара хокук принципларына ныклы иярүенең ныгытылуын аерата билгеләргә кирәк. Конституция гражданин һәм дәүләтнең үзара җаваплылыгын билгеләде, ТРның дәүләт телләре итеп татар һәм рус телләрен игълан итте, ТРның бөтенлеген һәм конституцион строен көчләп үзгәртүне максат иткән партия, оешмалар һәм хәрәкәтләр булдыруга һәм эшчәнлегенә юл куймаган хәлдә, күп партияле системаны ныгытты. ТР Конституциясе беренче тапкыр ТРның хуҗалык эшчәнлеге шәхси, дәүләт милке, җирле үзидарә Советлары һәм иҗтимагый берләшмәләр милекләре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Ул беренче тапкыр җир участоклары һәм закон тарафыннан тыелмаган эшчәнлек сферасында кулланыла торган башка объектларга шәхси милекчелек мөмкинлеген ныгытты.

Төп Законда ТР икътисадының базар мөнәсәбәтләре принциплары нигезендә эш итүе турында положение ныгытыла.

Конституциядә ТРсының үз гражданлыгы булу ныгытыла.

ТР гражданнары Россия Федерациясе - Россия гражданлыгына да ияләр. ТР гражданнары ике гражданлыкны саклый яисә аннан баш тарта алалар.

ТРсының барлык гражданнары тигез хокук һәм бурычларга ияләр.

Гражданнарга туган теленнән файдалану гарантияләнә.

ТР Конституциясе хәрби хезмәтне Закон тарафыннан билгеләнгән альтернатив бурычлар белән алыштыру мөмкинлеген карый.

ТРның дәүләт төзелешенә Конституциядә аерым бүлек багышланган.

ТРсы башка дәүләтләр белән мөнәсәбәткә керә, халыкара килешүләр төзи, дипломатик консуллык, сәүдә һәм башка вәкилләр белән алмаша, халыкара хокук принципларына нигезләнгән халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша ала. Конституция үз компетенцияләренә караган барлык мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итүче дәүләт властеның вәкаләтле органнары итеп халык депутатларының бердәм системасын саклый.

ТРның гамәлдәге конституциясе кабул ителгәннән соң узган 5 елда Дәүләт Советы тарафыннан 126 закон кабул ителде.

ТР Конституциясе нигезендә, республикада дәүләт башлыгы булып Президент тора. Ул Татарстан Республикасы гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен, дәүләт мөстәкыйльлеген, республиканың территориаль бөтенлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итә, дәүләт белән идарә итү органнары системасын җитәкли һәм аларның Дәүләт Советы белән мөнәсәбәтләрен тәэмин итә, җирле хакимиятләргә юнәлеш бирә, халык депутатлары Советлары белән килешеп район һәм республика буйсынуындагы шәһәр, хакимият башлыкларын билгели һәм азат итә; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын формалаштыра һ.б.

ТР Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы хөкүмәте - Конституция нигезендә ТРсы дәүләт властеның башкарма һәм күрсәтмә органы булып тора һәм ТР Президентына буйсына.

Татарстан Республикасында җирле үзидарә конституция нигезендә шәһәр, авыл пунктларында һәм башка территорияләрендә башкарыла һәм законга яраклаштырып җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итүне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасында суд власте Конституция нигезендә бары суд органнарына гына карый.

Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеген, Татарстан халкының традицияләрен һәм үзенчәлекләрен характерлаган Дәүләт Символы булып Дәүләт флагы, Дәүләт гербы, Дәүләт гимны санала, ул Конституция нигезендә ТРсы дәүләт Советы тарафыннан. раслана.

# ЧИСТАЛЫК ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕК САГЫНДА

**Быелның 15 сентябрендә РФ һәм ТР санитария - эпидемиология службалары үзенең 75 еллыгын билгеләп үтте.· Күптән түгел юбилей шаукымы безнең район санитар - эпидемиологларына да килеп җитте: алар аны тантаналы төстә үткәреп җибәрделәр.**

Район санитария службасының гомере 6 дистәләр чамасы белән исәпләнсә дә, тарихы илнекеннән бик азга гына аерыла. Шул ук проблемалар, шул ук киртәләр озата бара аларны. Тантанада чыгыш ясаучылар ЦГСЭНның баш табибы И.В.Әндәров һәм элеккеге баш табибы Л.П.Кармальская нәкъ шул хакта сөйләделәр.

«Санитария - халык сәламәтлеген саклау һәм чисталык булдыру»- диелә С.Ожеговның аңлатмалы сүзлегендә. Гади итеп әйткәндә, нәкъ шул вазифаларны үтәргә алына да служба. 1922 ел. Чәчәк, тимгелле тиф, трахома, йогышлы эчәк авыруларының котырынып таралган чагы. Санитария службасының матди базасы да, махсус кадрлар да әле юк дәрәҗәсендә. Сугыш вакытында ул яңа, җитди сынауларга тара.

Ул елларда Норлатта Октябрь, Тельман, Әлки, Беренче май (хәзерге Чирмешән), Аксубай районнары халкына хезмәт күрсәтә торган районара санэпидслужба оеша. Анда барысы 7 кеше эшли. Ул чакта СЭС район Советы башкарма комитетының элеккеге бинасында бер кабинетны биләп тора. 1951 - 52 елларда аңа «яңа бина» төзү өчен Савин авылы мәчете тапшырыла. 1971 - 74 елларда бүгенге коллективның горурлыгы - республикада хуҗалык ысулы белән беренче яңа типтагы бина төзелә. Л.П. Кармальская, Н.Г.Сафин, Е.А.Епифанов - бу эшнең башында торган, һәр кирпечне, һәр уч комны үз куллары аша үткәргән кешеләр.





Бүген ул иң кирәкле матди - техник база белән тупланган. Кадрлар белән тәэмин ителеш ягыннан да ул республикада квалификацион категорияле составы буенча иң алдынгылардан санала. Коллективта 53 кеше эшли, шуларның 9сы табиблар. Инде 7 ел коллективны югары категорияле табиб И.В. Әндәров җитәкли.

Кыскасы, районның санитария - эпидемиология таләпләрен үтәү, аның бурычларын тормышка ашыру өчен бөтен шартлар да тудырылган. Күптән түгел ТРның санэпидкүзәтү дәүләт комитеты тарафыннан биш елга бер үткәрелә торган планлы комплекслы тикшерү вакытында да Октябрь районы санэпидкүзәтү үзәге эшчәнлеге югары бәяләнде. Хәер, үзәкне бәйрәм белән котларга килүчеләрнең дә күпчелеге аның республикада абруйлы урын тотуы хакында сөйләделәр һәм мисаллар китерделәр. Шатлыкны бүлешергә район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова, район үзәк шифаханәсе баш табибы А.Л.Клементьев, территориаль шифаханә кассасы башкарма директоры З.А.Шабаев һәм санитария службасы белән тыгыз элемтәдә торучы кайбер предприятие җитәкчеләре килгән иде.

Санитария - эпидемиология өлкәсендә күп еллар буе фидакарь хезмәтләре өчен И.В.Әндәров ТР санэпидкүзәтү дәүләт комитеты, ә табиб - лаборант Л.К.Кузнецова һәм санитария табибы ярдәмчесе М.Г.Мирзагалимова район хакимияте Мактау грамоталары белән бүләкләнделәр. Шулай ук бөтен гомерләрен шул авыр хезмәткә биргән кешеләр Л.П. Кармальская, Е.А.Епифанов, М.М.Рәхмәтуллина, Л.П.Кутузова, Р.В.Сидорова адресына иң җылы сүзләр әйтелде. Бүген биредә алгы сафта үз һөнәрләренең осталары С.П.Зотова, Ф.Х. Хәсәншина, Ф.М. Шәйдуллин, Л.Н.Яллина, М.Ә.Мостафина һәм башкалар.

Шунысын әйтергә кирәк, алар редакция белән дә тыгыз элемтәдә торалар, журналистлар белән берлектә үткәрелгән рейдлардан аларның исемнәре газета укучыга да таныштыр, мөгаен.

Кунаклар юбилейга буш кул белән килмәгән, хуҗалар да үз чиратларында сый - хөрмәт белән каршы алып озаттылар.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

**Рәсемдә: юбилейдан күренеш; район санэпидкүзәтү үзәге хезмәткәрләре.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

### *Әңгәмәдәшебез - хакимият башлыгы урынбасары*

# Сезоннарның «кайнар» булмаганы юк

***Норлат автоюллар идарәсендә гадәти эш көне иде: бер - бер артлы өзлексез шалтыраган телефон аркылы гына да кабинет хуҗасы - идарә начальнигы Һ.Х.Садыйков санаулы вакыт эчендә ничәмә - ничә проблема хәл итте, күрсәтмәләр бирде. Тегесе дә, бусы да аерым бер НУАДныкы гына түгел, тулаем районда юл төзелеше, газлаштыру мәсьәләләренә кагылышлы булды. Һәм безнең Һ.Садыйков белән әңгәмәбез дә район хакимияте башлыгының юл төзелеше һәм газлаштыру буенча урынбасары буларак, тулаем район күләмендә юл төзелеше хакында барды.***

**- Һади Харисович, юл төзүчеләр өчен 1997 нче елның «кайнар» сезоны нинди эшләр белән истә калыр икән?**

- Киеренке, югары нәтиҗәле хезмәт белән дияр идем мин. Барлык юл төзү оешмалары да ал - ял белән исәпләшмичә эшләделәр. Апрель азагыннан бүгенге көнгәчә ДРСУ гына да 30 километрдан артык мәйданда эш башкарды. Илюткино белән Фома, төп юлдан Бутаихага кадәр булган араларга яңа асфальт - бетон юллар салынды. Кычытканлыга кадәрге юлны да алар төзи башлады. Болардан тыш, Норлат - Мамык трассасында шактый арада ремонт эшләре дә башкардылар әле.

НУАДның эшләре дә күләмле булды. Әхмәттән Бикколга кадәрге 6 километр, Киекле эчендәге 2 километр арага асфальт - бетон түшәлде, Үрнәк авылы эчендә дә юлларны төзекләндерү буенча шактый эш башкарылды. НГДУ заказы буенча Камышлыдагы ДНСка юл салынды. Хәер, нефть объектлары тирәсендә һәрдаим эшли идарә. Норлат - Әлмәт трассасында 10 километрда башкарылган ремонт эшләре дә бик вакытлы булды. 4 километр ара исә капиталь ремонтланды. НУАДның аэропорт территориясендә башкарган эше дә саллы булды. Очу полосасына икенче кат асфальт - бетон түшәлсә, территориягә керә торган мәйдан яңабаштан эшләнде.

Карл Маркс урамының җөп ягыннан салынган киң тротуар да НУАДлар эше. Үтеп йөри алмаслык сазлык, баткаклыклы Нариманов урамына да асфальт - бетонны әлеге оешма юл төзүчеләре түшәде.

РСУ да җәйге сезонда «кызу» эшләде. МПП заказы буенча шәһәрнең төрле почмакларында да тротуарлар салды, яңартты, мәйданчыклар төзекләндерде. Яңа оешма - чикләнгән җаваплылыктагы «Татдорстрой» автомобиль юллар төзү идарәсе (ОСАД)дә район тарихында эзле калыр: мөһим объект - Түбән Норлаттан Дала Мамыгына кадәрле юлга Урта Идел зонасында бердәнбер булган ДС - 99 автогрейдеры белән башкарылышы һәм сыйфаты буенча районда әлегәчә күрелмәгән юл салынды. Юл төзелешенең планлаштырылган кадәрледән күпкә артык мәйданда үткәрелүе - хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның якыннан торып кызыксынуы һәм ярдәме нәтиҗәсендә мөмкин булды.

**- Еш кына юл төзүчеләрне начар юллар салуда гаеплиләр. Бу сүзләр ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә?**

- Юк дип кире кагарга җыенмыйм. Элегрәк андый очраклар булды. Быелгы елга кадәр юлларны без үзебез генә кабул итә идек. Республикада юл фонды оешкач, гомуми куллanудагы барлык юлларны да ул кабул итеп ала. Түшәлгән полотнодан алынган анализдан чыгып фикер йөртелә. Бу очракта юл сыйфатсыз төзелгән дип табылса, аны кабаттан салу шул ук оешма исәбеннән башкарыла. Шуңа да юл төзү оешмалары әлеге проблемага бөтен җаваплылыгы белән якын киләләр хәзер. Ә гомумән алганда, югары сыйфатлы юллар төзү бик катлаулы эш. Мисал өчен юл салганда бер генә компонент җитешмәсә, яисә кәтүкләр җитәрлек дәрәҗәдә юлны кәтүкләмәсә, бу һичшиксез сыйфатка суга. Аннары, юл салу техникасының шактый ук таушалуы да сыйфат файдасына түгел.

Сүз уңаенда, юлдан файдаланучылар, аеруча авыл хуҗалыгы ассоциацияләренең юлларга сак карамаулары турында да әйтер идем. Чылбырлы, авыр йөк күтәрешле техника йөри бит безнең юллардан. Аларның билгеләнмәгән урыннардан басуга төшеп китүләре дә юлга зур зыян сала. Сакланган гына саклана - шуны онытмасыннар иде алар.

**- Шулай да безнең юллар ызандаш районнарныкыннан сизелерлек аерылып тора бит. Гомумән, тулаем районда кайчан бөтен юллар да асфальт түшәүле булыр икән?**

- Әйе, безнең юллар күрше районнарныкыннан күпкә яхшы. Әмма бу әле тынычланырга урын бирми. Ни өчен дигәндә, район буенча исәпләнгән 400 километрлап юлның 227 километры гына асфальт - бетон түшәүле. Кизләү, Якты Күл, Тукай, Иске Авыл һәм кайбер башка авыллар һаман да юлсызлыктан иза чигәләр. Шуңа да якындагы берничә елда әлеге читтәге авылларны төп автомобиль магистральләренә тоташтыруны максат итәбез. ДРСУ, мәсәлән, киләсе елда төп юлдан Иске Әлмәткәчә юл салачак. Колбай Мораса авылы эченә туры юлны да алар салачаклар.

НУАДка да бурычларның зурысы йөкләнә. Камышлыдан Вишневая Полянага кадәрле, Түбән Чаллыга кадәрге арага юл салыначак. Кизләүлеләр дә киләсе елдан юл газабыннан арыначаклар. Быел Үрнәк авылы эчендә башланган асфальтлау эше киләсе елда тулысынча төгәлләнәчәк, биредә күпер дә салыначак әле. Күпер дигәннән, киләсе елда Богдашкино авылы янындагы иске күпер урынына яңасын салу күздә тотыла. Керү - чыгу юлларын төзекләндерүче оешма да билгеле - НУАД.

ОСАД та эш фронтына аптырамаячак. Каравыл Тавы белән Төрнәс авыллары арасындагы урман юлын «зигзаглы»дан турыга әйләндерү кебек бурыч аларга йөкләнде. Фома авылын Самара өлкәсенә дә асфальтлы юл белән ОСАД тоташтырачак... Каравыл Тавы күпере тирәсен төзекләндерү дә әлеге берләшмәгә йөкләнде.

Алда телгә алынган эш төрләре - иң күләмлеләре. Болардан тыш, төрле трассаларда планлы һәм капиталь ремонт үткәрү ният ителә. РСУ исә гадәттәгечә шәһәр эчендәге юллар, тротуарларны төзекләндерү белән мәшгуль булачак.

**- Юл төзү оешмаларының матди базаларын үстерү күздә тотыламы?**

- Һичшиксез. ДРСУның асфальт - бетон заводларының берсе бик иске. Киләсе елда шуның урынына яңа завод кору планлаштырыла. НУАДта төзелә торган 30 автомашиналык гаражда киләсе елда сафка керергә тиеш. Идарә шулай ук җыелган суларны чистарту өчен корылма төзүне дә кичектергесез бурыч дип саный.

Болардан тыш, ДРСУ һәм НУАД район җитәкчелегенең ярдәме белән заманча асфальт җәю җиһазлары сатып алырга да ниятли.

**- Һади Харисович, юлчылар өчен кышкы - язгы чор «йомшару», көч туплау сезонырдыр инде...**

- Киресенчә. Язгы - җәйге сезонда эшне бер көйләп җибәрсәң, шул ритмны гына «тотып» барасы була. Ә кышын... Беренчедән, киләсе юл төзү сезоны өчен җитәрлек кадәр материал туплыйсы бар. Ә аңа ихтыяҗ зур. Мисал өчен НУАДка гына да 60 мең тонналап ком - гравий измәсе, 40 мең тонна вак таш, 10 мең тонналап ком кирәк. ДРСУ, ОСАД, РСУның да бу төр материалларга ихтыяҗы шул чама. Килешүләр төзү, кайтарту, проект - смета документацияләре хәзерләү... Аннары кышкы чорда юлларны карау да четрекле эш. Бозлавык юлларны эретү өчен трассалар, тротуарларга тозлы ком сибүне оештыру, кар - бураннар «котырган» очракка төзек юл чистарту техникасы белән кешеләрнең тәүлек буена даими дежурлыгын булдыру зур оешканлык һәм чыгымнар таләп итә. Инде менә бүген үк ТР Министрлар Кабинеты эшләгән «Буран» программасы нигезендә без дә үз районыбыз җирлегеннән чыгып планнар корабыз: алдан аяк киенмәсәң, вакыты җиткәч авыр хәлдә калуың бар.

**- Тулаем районда юл төзелеше өчен җаваплы кеше буларак, нинди планнар, үй - теләкләр белән яшисез?**

- Яхшы юллар - район өчен зур нәрсә. Якын киләчәктә гомуми файдаланудагы гына түгел, поселокара, авыл хуҗалыгы объектлары арасында да сыйфатлы, яхшы юллар саласы иде.

**Әңгәмәдәш - Р.ГИНЯЕВА.**



Заһитның шофер буласы гамәл дәфтәренә язылганлыгына шикләнәсе юк. Әтиләре Ирек абый гомерлек шофер, абыйлары Таһир белән Талип та шул һөнәрне сайладылар. Һәм Заһитның гаилә династиясен дәвам итүе гаҗәп булмаган кебек, аның эшен дә тел - теш тидермәслек иттереп башкаруына да аптырыйсы юк. НГДУның технологик транспорт идарәсенә эшкә урнашуына да ундүртенче ел инде аның. Машинаның шушы тармак өчен махсус булганнарында да күрсәтте үзен, инде үзбушаткыч КамАЗда да менә дигән иттереп эшли. Быелгы уракта МТСның «Кейс» комбайннарыннан торган җыелма отряды составында булды ул һәм җәй буена район басуларын ничәмә -ничә тапкыр аркылыга буйга йөреп чыкканлыгын, элеваторга ничә йөк ашлык китергәнлеген үзе дә төгәл белми торгандыр. Хәер, Заһит эш дигәндә алай санашып - исәпләшеп тора торганнардан түгел, алынган хезмәтен җиренә җиткереп башкарудан башканы белми. Иген урагы төгәлләнгәч икенчесенә тотынды - чөгендер ташый ул хәзер. Кая җибәрсәләр шул хуҗалыкка чыгып китә, бу арада «Заря» белән «Игенче»дән ешрак ташырга туры килә. Хуҗалыкларда тоткарлык булмаса, көненә дүртәр рейс ясамый калганы юк.

**Рәсемдә: УТТ шоферы З.Мөхәммәдиевны фотохәбәрчебез Н.Азизов җәйнең иң кызу чагында, җыелма отряд белән «Заря»да эшләгәндә рәсемгә төшереп алган иде. Әмма Заһит өчен бүген дә эшнең кызу чагы.**

# Рухи берҙәмлек өчен

**25 - 26 октябрьдә Чувашия башкаласы Чабаксарда чувашларның III конгрессы булды. Безнең корреспондентыбыз конгресс делегатлары һәм кунакларын аннан алган тәэсирләре белән уртаклашуын үтенде.**

**Юрий Владимирович Терентьев, район хакимияте башлыгының беренче урынбасары:**

- Бу форумда Татарстаннан 60 кешелек делегация катнашты, безнең районнан рәсми рәвештә 4әү һәм бер гаилә барды. Без уртак милли тамырлары булган халыкның зур аралашу бәйрәмендә шатланып катнаштык. Эчтәлеге ягыннан ул иң элек төп нәрсә - халыклар арасында игелекле мөнәсәбәтләр ныгуына булыша, Чувашия безнең якын күршебез бит.

**Лидия Николаевна Дилмөхәммәтова, халыкны социаль яклау идарәсе начальнигы.**

- Конгресстан алган тәэсирләребез күп. Академия театры бинасында узган бу чарада бик күп кеше катнашты, анда бәйрәмчә атмосфера хөкем сөрде. Конгресс университет юбилее белән бергә туры килде, шуңа биредә мәгърифәт ноталары бик ачык күренә иде: күпләп чуваш телендә китаплар, журналлар һәм башка басмалар тупланды. Тантанада Чувашия Республикасы Президенты Н.Федоров катнашты һәм чыгыш ясады - без, сүз уңаеннан, аңа чигүле кәләпүш бүләк иттек. Чыгышлар, гомумән, күп һәм күптөрле проблемаларга кагылышлы иделәр.

**Аркадий Леонтьевич Клементьев, район үзәк шифаханәсе баш табибы.**

- Чабаксарда минем икенче тапкыр гына булуым иде. Шуңа күзгә иң элек ташланганы - республиканың бер дигән итеп асфальтланган юллары, бай табигате, җыйнак авыл өйләре, чиста шәһәр һәм кунакчыл халык. Конгресска делегатлар һәм кунаклар Россиянең төрле төбәкләреннән - Санкт - Петербургтан, Төмәннән, Воркутадан килгәннәр иде. Шуңа карамастан, чуваш халкының дәүләтчелеген, телен, мәдәниятын, традицияләрен саклау турында сөйләшү эшлекле һәм нәтиҗәле акты. Бәйрәм кулуарларында без үз төбәкләребездәге тормыш - көнкүрешләр турында сөйләштек, бу аралашу безне тагы да якынайтты.

*Сез үз хокукларыгызны беләсезме?*

# КИТЕРСӘГЕЗ ДӘ АЛМАСЛАР...

***Мәгълүм булганча, сатып алучы кибеттән, базардан, төрле коммерция нокталарыннан алган һәм нинди сәбәптән булса да күңелен канәгатьләндермәгән азык - төлек булмаган товарны 14 көн эчендә кире алыштыра яки тапшыра ала. Әмма алыштырылмый торган товарлар да барын беләсезме?***

***Район кулланучылар хокукын яклау комитеты, тиешле күрсәтмәләргә таянып, шундый товарлар исемлеген бәян итә. Алар исемлегенә түбәндәгеләр керә:***

- Кыйммәтле металлдан, кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле ташлардан эшләнгән әйберләр.
- Барлык төр җепселләрдән эшләнгән тукымалар һәм башка метрлы товарлар (тасмалар, челтәрләр һ.б.).
- Олылар һәм балалар өчен эчке трикотаж киемнәр.
- Коену костюмнары.
- Олылар һәм балалар өчен трусылар, шул исәптән спорт трусылары.
- Яңа туган һәм ясли яшендәге балалар өчен эчке киемнәр.
- Урын - җир әйберләре.
- Хатын - кыз туалеты әйберләре.
- Оек - носки әйберләр.
- Данәле текстиль товарлары (эскәтерләр, салфетлар, çөлгеләр, кульяулыклар һ.б.).
- Парфюмерия - косметика әйберләре.
- Көнкүреш химиясе товарлары.
- Ризык әзерләү һәм саклау өчен кулланыла торган пластмасс әйберләр.
- Шәхси гигиена предметлары (теш щеткалары, расческалар, бигудилар һ.б.).

Әлеге товарларны башта ук әйбәтләп сайлап алыгыз, соңыннан алыштыруга исәбегез барып чыкмаячак бит!

# КӨЗ БЕЛӘН ХУШЛАШУ



Минем укучыларым өченче ел инде фикерләү һәм иҗат үсешенә киң юл ача торган яңа предметлар өйрәнеп гимназия классларында укыйлар. Әмма «гимназистлар» кызыклы ял итә дә беләләр. Күптән түгел, мәсәлән, безнең класста отряд вожатыйлары Олеся Трачковская һәм Катя Королева ярдәмендә «Алтын көз» бәйрәме үтте. Балалар анда нинди генә фантазия һәм иҗади теләк белән костюмнар әзерләмәгәннәр: менә сылу миләшкәй, бусы чын - чын помидор, Катя исә гөмбә костюмыннан, көзге яфраклардан - Зина. Яшелчә һәм җиләк - җимешләрдән ясалган һәртөрле уенчыклар яныннан да тиз генә китәсе килми. «Көз» һәрберсен үз хәзинәләре - алмалар, кишер, кәбестә белән сыйлады. Соңрак иң олы кунагыбыз «Уңыш - 97» балаларны район игенчеләренең басуларда ирешкән уңышлары белән таныштырды, аларга һәртөрле сораулар бирде, табышмаклар әйтте, конкурслар оештырды. Нәниләр арасында уен - көлке озак тынмады.

**В.ЖУЛИНА.**
**3 нче мәктәп.**

## *Чикләвекле кишер салаты*

**4 кешегә:** 4 кишер, 2 чәй калагы сок, 1 аш кашыгы үсемлек мае ( ис килә торган булмасын), 100 грамм төелгән урман чикләвеге яки кузы чикләвеге.

Кишерне эре тишекле кыргыч аша уып, чикләвек өстәгез. Лимон согын май белән аерым болгатып, кишер өстенә сибегез.

Мондый салатны итле һәм балык ризыкларына кушып ашагач тәмле була.

*Имеш*

# ЭЧКӘН БУЛГАН

Экспертиза, юл фаҗигасендә һәлак булган принцесса Диана утырган машина шоферы эчкән булган, дигән нәтиҗәгә килә. Франциядә кеше каның 1 литрында 0,5 миллиграмм спирт норма санала. Ә руль артында утырган «Ритц» кунакханәсе иминлеге начальнигы канында ул 1,75 миллиграмм була. Бу - ике шешәдән артык вино эчкәнлекне күрсәтә.

# *КОТЛЫЙБЫЗ*



Биккол авылында яшәүче әтиебез **Гомәр Гали** улы һәм әниебез **Гөлфия Зиннәтулла** кызы **Сәйфуллиннарның** 6 ноябрьдә көмеш туйлары.

Әти, әни, яшәгез сез
Авырлыкларны белмичә.
Тормыш юлларыгыз үтсен
Кайгы - хәсрәт күрмичә.
Безнең күңел һәрчак сезгә
Телидер изге теләк.
Җир йөзендә сездән башка
Берни юк кадерлерәк.

**Улы, кызлары, кияве.**

**Әнисә Тәлгать кызы Әхмәтшинаны** 35 яшь тулган көне белән тәбриклибез. Аның гаиләсе белән бергә тигез гомер итүен телибез.


Һәлакәтләр сине читләп үтсен,
Күңеленә кайгы тулмасын.
Ходай сиңа озын гомер бирсен,
Шатлыгыңның чиге булмасын.

**Изге теләкләр белән әниең, кызың, апаң.**

Кадерле әтиебез, дәү әтиебез **Равил Габдрахман** улы һәм әниебез, дәү әниебез **Гөлнур Мирза** кызы **Билаловларны** чын күңелдән көмеш туйлары белән котлыйбыз.

Бүләгебез - саф теләкләр
Сезгә, әткәй, әнкәй, кабул итегез.
Изгелектә, игелектә,
Иминлектә гомер итегез.

**Кызлары Эльвира һәм Гөлнара, кияүләре Радик, оныклары Раил һәм Илнар.**



Норлатта яшәүче **Йосыф Исхак улы Ганиевка** 10 нчы ноябрьдә 60 яшь тула. Аны чын күңелдән юбилее белән тәбрик итәбез, нык сәламәтлек, озын гомер, җан тынычлыгы телибез.

Олыгайдым диеп уфтанма,
Күңелең иркен, һаман яшь әле.
Тагы да шулай картаюны белми
Кайгы - хәсрәт күрми яшәле.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәше, Ярулликннар һәм Мәгыйзовлар гаиләләре.**

Норлатта яшәүче кадерле әниебез, әбиебез **Галия Вәлиәхмәт кызы Әхмәтшинаны** 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

Котлы булсын, әни, туган көнең,
Юлларыңа гөлләр сибелсен.
Киләчәкнең алсу таңы сиңа
Мәңге сүнмәс шатлык китерсен.

**Балалары, оныклары.**

# ТЕГЕРМӘНЧЕДӘН УҢДЫК

«Күмәч ашагыз, сәламәт булыгыз»- ди ул канәгать елмаеп клиентларын озатканда. Сүзем авылыбызның мөхтәрәм кешесе, үз эшенең остасы булган ак он тегермәнчесе Сөләйман ага Хөсәенов турында. Халык өчен бик кирәкле хезмәтне башкара ул. Биредә һәрвакыт зур җанлылык хөкем сөрә, һәркөнне кеше өзелми. Ерак араларны якынайтып күрше - тирә авыллардан да киләләр. Ә ак он тегермәненең нормаль эшләве аның хуҗасының үз эшен зур җаваплылык тоеп, күңел биреп, халык өчен тырышып башкаруындадыр. Авыл халкы аның эшеннән бик канәгать. Өстәлләребездәге ап - ак кабарып пешкән икмәккә, иң элек игенчеләребезнең тырыш хезмәте керсә, биредә тынгысыз Сөләйман аганың да өлеше бар, билгеле. Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: Сөләйман ага, киләчәктә дә халык өчен тырышып хезмәт ит! Исәнлек - саулык бирсен сиңа ходай! Газета аша авыл халкы исеменнән мең рәхмәт сиңа!

**З.ИСМӘГЫЙЛОВА.**
**Кычытканлы авылы.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Норлат шәһәрендә яшәүче кадерле әниебез **Рәхилә** һәм әтиебез **Газыйм Идиятуллиннарның** бергә тормыш коруларына 30 ел була. Аларга саулык - сәламәтлек, бәхетле озын гомер, тигез тормыш һәм безнең игелегебезне күреп, иминлектә яшәвегезне телибез.

Тигез гомер насыйп булсын сезгә
Гел атлагыз бергә янәшә.
Сау - сәламәт, изгелектә булып
Яшәсәгез иде йөзгәчә.

**Иң изге теләкләр белән кызларыгыз, кияүләрегез һәм оныкларыгыз.**


## *Белдерүләр*

***САТАБЫЗ***

**1982 елда чыккан ВАЗ - 21011.** Тел.: 3 - 52 - 46.

***

**Әрҗәле УАЗ.** Кошки авылында Молодежная ур., 17 нче йортка теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итәргә.

***

**Мамык авылында дача өчен йорт, кыйммәт түгел.** Адрес: Советская ур., 66 - 11.

***

**1997 елның мартында чыккан ВАЗ - 21070, «Мурена» төсендә, 5 баскычлы тапшыру тартмасы, сигнализация, 10 мең км. юл үткән.** Адрес: Нефтчеләр ур., 1[illegible] - 20. Тел.: 65 - 3 - 05 (16 сәг.тән соң.).

***

**Шәһәр үзәгендә өч бүлмәле фатир.** Адрес: Советская ур., 143 - 13, 14 сәг.тән соң.

***

**1992 елда чыккан, әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2105.** Тел.: 3 - 83 - 90

***

**Тимер юл балалар бакчасы янында ике бүлмәле фатир.** Адрес: Линейная ур, 13 - 1, 17 сәг.тән соң.

***

**КамАЗ - 55102, үзбушаткычлы «Колхозник», ВАЗ - 21074 (1995 елгы).** Тел.: 2 - 13 - 61.

***

**Южная ур., 8 һәм Линейная урамында йортлар.** Ключи поселогында Сатдаров Әхтәмгә мөрәҗәгать итәргә.

***

***АЛМАШТЫРАБЫЗ***

**Гыйматдинов исем. ур., 162 нче йорттагы ике бүлмәле фатир ике берәр бүлмәлегә алыштырыла (шикәр заводы районы һәм тимер юлчылар поселогын тәкъдим итмәскә),** тел.: 2 - 21 - 89.

***

**Төньяк микрорайонында төзелеп бетмәгән йорт 3 бүлмәле фатирга.** Тел.: 2 - 11 - 33.

***

***ТӨРЛЕСЕННӘН***

**Халыкка хезмәт күрсәтү буенча «Надежда» дәүләт предприятиесенә тире эшкәртү цехына начальник кирәк.**

***

**Тәҗрибәле Казан юристы: консультацияләр, эзләп алу гаризалары, судта яклау һәм вәкил булып тору, арбитраж, учредитель документлары, юридик аудит. Коммерция оешмаларына комплекслы хезмәт күрсәтү.** Мөрәҗәгать итү өчен адрес: Гыйматдинов исем. ур., 79, 2 нче кат.

## *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 7, 21ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.